**«Муниципаль районның аерым мәсьәләләрен хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында» Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Түбән Өскебаш авыл җирлеге Советы карары**

«18» ноябрь 2022 ел № 26

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Өскебаш авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Советына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы җирле үзидарә органнарының түбәндәге вәкаләтләрен Түбән Өскебаш авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарына тапшыру турындагы мәсьәләне карарга тәкъдим итәргә:

муниципаль торак фондын исәпкә алу;

Гражданнарны аз керемлеләр дип тану һәм аларга муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча торак урыны бирү максатларында гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган керем күләмен һәм гаилә әгъзалары милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакын билгеләү;

социаль файдалану торак фондының торак урыннары наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирүгә мохтаҗлар дип тану максатларында гражданнарның һәм алар белән даими яшәүче гаилә әгъзаларының керемнәрен һәм аларның салым салынырга тиешле мөлкәтенең хакын билгеләү;

социаль файдалану торак фондының торак урыннары наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирүгә мохтаҗлар дип тану максатларында гражданнарның һәм алар белән даими яшәүче гаилә әгъзаларының керемнәрен һәм аларның салым салынырга тиешле мөлкәтенең максималь күләмен билгеләү;

билгеләнгән тәртиптә социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗлар буларак гражданнарны исәпкә алуны алып бару;

социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алырга;

аз керемле гражданнарга муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча билгеләнгән тәртиптә торак урыннары бирү;

муниципаль махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннары бирү тәртибен билгеләү;

муниципаль торак фондында булган хезмәт торагын наем шартнамәсе буенча торак урыннары бирүгә мохтаҗ буларак гражданнарны исәпкә алу;

гражданнарга муниципаль торак фондында хезмәт урыны буенча торак наемы шартнамәләре буенча торак урыннары бирү;

махсуслаштырылган торак фонды составына торак биналарны кертү һәм төшереп калдыру;

социаль наем шартнамәсе буенча бирелгән муниципаль торак фондының торак урыннарын алмаштыру буенча документларны рәсмиләштерү.

2. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Советы әлеге

карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдимне кабул иткән очракта, Кукмара муниципаль районы Түбән Өскебаш авыл җирлеге башкарма комитеты әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзи.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча, махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Түбән Өскебаш авыл
Җирлеге башлыгы Н.М.Мөхәммәтҗанов